МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ
Федеральное государственное автономное учреждение
высшего профессионального образования
"Казанский (Приволжский) федеральный университет"
Высшая школа татаристики и тюркологии им.Габдуллы Тукая

УТВЕРЖДАЮ

Проректор по образовательной деятельности КФУ

Проф. Таюрский Д.А.

__________________ "___" ______________20___ г.

*подписано электронно-цифровой подписью*

# Программа дисциплины

Татарская литература начала 20 века Б1.В.ОД.16.4

Направление подготовки: 44.03.05 - Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)

Профиль подготовки: Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (английский)

Квалификация выпускника: бакалавр

Форма обучения: очное

Язык обучения: русский

**Автор(ы):**

Гилазов Т.Ш.

**Рецензент(ы):**

Закирзянов А.М.

**СОГЛАСОВАНО:**

Заведующий(ая) кафедрой: Сайфулина Ф. С.
Протокол заседания кафедры No ___ от "____" ___________ 201__г

Учебно-методическая комиссия Института филологии и межкультурной коммуникации (Высшая школа татаристики и тюркологии им.Габдуллы Тукая):
Протокол заседания УМК No ____ от "____" ___________ 201__г

Регистрационный No 902328018

Казань

2018



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

## Содержание

1. Цели освоения дисциплины
2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы
3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля
4. Структура и содержание дисциплины/ модуля
5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения
6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов
7. Литература
8. Интернет-ресурсы
9. Материально-техническое обеспечение дисциплины/модуля согласно утвержденному учебному плану


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Программу дисциплины разработал(а)(и) доцент, к.н. (доцент) Гилазов Т.Ш. кафедра татарской литературы Высшая школа татаристики и тюркологии им.Габдуллы Тукая , Tagir.Gilazov@kpfu.ru

## 1. Цели освоения дисциплины

Целями освоения дисциплины "История татарской литературы начала XX века" являются ознакомление с произведениями писателей начала XX века, хронологией их жизни и творчества, дать представление о направлении творческой эволюции татарских авторов, об особенностях поэтики и проблематики их наиболее значительных произведений, их отношений к различным художественным системам, а также о динамике развития национальной литературы, основных литературных направлениях, школах.

## 2. Место дисциплины в структуре основной образовательной программы высшего профессионального образования

Данная учебная дисциплина включена в раздел " Б1.В.ОД.16 Дисциплины (модули)" основной образовательной программы 44.03.05 Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки) и относится к обязательным дисциплинам. Осваивается на 3 курсе, 5 семестр.

Данная учебная дисциплина входит в раздел "Б.3. Профессиональный цикл. Базовая часть". ФГОС-3 по направлению подготовки 050100 Педагогическое образование (квалификация (степень) "бакалавр")". Для изучения дисциплины необходимы компетенции, сформированные у обучающихся в результате обучения в средней общеобразовательной школе и в результате освоения дисциплин ООП подготовки бакалавра "Введение в литературоведение", "Устное народное творчество", "Татарская литература до XIX века", " Татарская литература XIX века", "Татарская литературная критkика".Дисциплина относится к системе дисциплин профессионального цикла, ориентированных на диахронное и синхронное изучение истории татарской литературы. Данная дисциплина предваряет циклы дисциплины специальностей ((прежде всего Педагогическое образование (Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (английский)), Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки) (Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (турецкий)), учебную практику и производственную практику по этим профилям.

## 3. Компетенции обучающегося, формируемые в результате освоения дисциплины /модуля

В результате освоения дисциплины формируются следующие компетенции:

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| ок-1 | владеет культурой мышления, способен к обобщению, анализу, восприятию информации, постановке цели и выьору путей ее достижения |
| опк-1 | осознает социальную значимость своей будущей профессии, обладает мотивацией к осуществлению профессиональной деятельности |
| опк-2 | способен использовать систематизированные теоретические и практические знания гуманитарных, социальных и экономических наук при решении социальных и профессиональных задач |
| пк-1 | способен реализовывать учебные программы базовых и элективных курсов в различных образовательных учреждениях |


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

| Шифр компетенции | Расшифровка приобретаемой компетенции |
|---|---|
| пк-2 | готов применять современные методики и технологии, в том числе и информационные, для обеспечения качества учебно-воспитательного процесса на конкретной образовательной ступени конкретного образовательного учреждения |
| пк-11 | способен выявлять и использовать возможности региональной культурной образовательной среды для организации культурно-просветительской деятельности |

В результате освоения дисциплины студент:

1. должен знать:

основные положения и концепции в области теории и истории литературы; теории филологического анализа; иметь представление об истории, современном состоянии и перспективах развития литературоведческой науки.

2. должен уметь:

применять полученные знания и навыки в области теории и истории татарской литературы в научно-исследовательской и других видах деятельности, уметь проводить сопоставительный анализ художественных текстов с учетом жанровых традиций, различных литературных направлений и течений, а также лингвистический анализ текстов с учетом их стилистической принадлежности.

3. должен владеть:

основными методами и приемами исследовательской и практической работы в области теории и истории татарской литературы, а также основными литературоведческими терминами и понятиями.

4. должен демонстрировать способность и готовность:

В результате освоения дисциплины обучающийся должен:

Знать: основные положения и концепции в области теории и истории литературы; теории филологического анализа; иметь представление об истории, современном состоянии и перспективах развития литературоведческой науки.

Уметь: применять полученные знания и навыки в области теории и истории татарской литературы в научно-исследовательской и других видах деятельности, уметь проводить сопоставительный анализ художественных текстов с учетом жанровых традиций, различных литературных направлений и течений, а также лингвистический анализ текстов с учетом их стилистической принадлежности.

Владеть: основными методами и приемами исследовательской и практической работы в области теории и истории татарской литературы, а также основными литературоведческими терминами и понятиями.

## 4. Структура и содержание дисциплины/ модуля

Общая трудоемкость дисциплины составляет 3 зачетных(ые) единиц(ы) 108 часа(ов).

Форма промежуточного контроля дисциплины экзамен в 5 семестре.

Суммарно по дисциплине можно получить 100 баллов, из них текущая работа оценивается в 50 баллов, итоговая форма контроля - в 50 баллов. Минимальное количество для допуска к зачету 28 баллов.

86 баллов и более - "отлично" (отл.);

71-85 баллов - "хорошо" (хор.);

55-70 баллов - "удовлетворительно" (удов.);


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

54 балла и менее - "неудовлетворительно" (неуд.).

### 4.1 Структура и содержание аудиторной работы по дисциплине/ модулю

### Тематический план дисциплины/модуля

| N | Раздел Дисциплины/ Модуля | Семестр | Неделя семестра | Виды и часы аудиторной работы, их трудоемкость (в часах) | | | Текущие формы контроля |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | Лекции | Практические занятия | Лабораторные работы | |
| 1. | Тема 1. Введение. Предмет, цели и задачи курса. Культурологическая характеристика начала XX века. Литературные направления и течения в татарской литературе Нового времени | 5 | 1-3 | 4 | 2 | 0 | Творческое задание |
| 2. | Тема 2. Татарская проза начала XX века. | 5 | 4-8 | 4 | 8 | 0 | Контрольная работа |
| 3. | Тема 3. Тататрская поэзия начала XX века. | 5 | 9-14 | 6 | 6 | 0 | Тестирование |
| 4. | Тема 4. Татарская драматургия начала XX века. | 5 | 15-18 | 2 | 4 | 0 | Контрольная работа |
| . | Тема . Итоговая форма контроля | 5 | | 0 | 0 | 0 | Экзамен |
| | Итого | | | 16 | 20 | 0 | |

### 4.2 Содержание дисциплины

**Тема 1. Введение. Предмет, цели и задачи курса. Культурологическая характеристика начала XX века. Литературные направления и течения в татарской литературе Нового времени**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

Тема: Кереш. Иҗтимагый-сәяси атмосфера һәм мәдәни хәл. Әдәби юнәлеш, стиль һәм агымнар. Мең елдан артык тарихы булган татар сүз сәнгате үсешендә XX гасыр башы татар әдәбияты. Аның хронологик чикләре. XX гасыр башында илдәге тарихи вакыйгалар, иҗтимагый-сәяси хәл. Беренче рус инкыйлабы, татар әдәбияты үсеше өчен ул тудырган алшартлар. Чор әдәбиятында XIX йөз татар әдәбияты реалистик традицияләренең иҗади үстерелеше, тәнкыйди (социаль) реализмга күчеше. Романтизм, аның ике тибы. Рус-Аурупа әдәби бәйләнешлары. Татар әдипләре иҗатларында модернистик агымнар сыналышы.

***практическое занятие (2 часа(ов)):***

Тема. Иҗтимагый-тарихи вакыйгалар һәм әдәби-мәдәни хәл. 1. XX гасыр башында дөньякүләм, ил һәм халык тормышында булган тарихи вакыйгалар, сәяси хәл. 2. Әдәбият һәм мәдәният дөньясындагы үзгәрешләр. 3. Татар вакытлы матбугаты туу һәм аның милли сүз сәнгатенә йогынтысы. 4. Татар әдәби тәнкыйтенең барлыкка килүе һәм матур әдәбият үсешендәге роле. 5. Милли профессиональ театр формалашу һәм татар әдәбияты. 6. XX гасыр башы татар әдәбиятында әдәби юнәлешләр һәм агымнар.

**Тема 2. Татарская проза начала XX века.**

***лекционное занятие (4 часа(ов)):***

Тема 3. XX гасыр башында милли проза. Гаяз Исхакый иҗаты. 1917 елларга кадәр татар прозасының үсеш баскычлары аерып чыгарыла. Үсеш этапларының идея-эстетик үзенчәлекләре ассызыклана, күренекле язучылар турында мәглүмат бирелә. XX гасыр башында яңа татар прозасына нигез салган күренекле язучы Гаяз Исхакый томыш һәм иҗат биографиясе хакында күзаллау тудырыла. Фатих Әмирхан (1886-1926) иҗаты Талантлы әдип, тәнкыйтьче, публицист, журналист һәм җәмәгать эшлеклесе. Ф.Әмирханның тормыш юлы, рухи һәм физик ныклыгы. Аның журналистлык һәм публицистик эшчәнлеге.Ф.Әмирханның милли әдәбиятны яңа баскычка күтәрүгә керткән өлеше. Эпик һәм драма төрендә эшчәнлеге. Әдип иҗатында гәүдәләнгән темалар, үткәрелгән төп фикерләр һәм идеяләр. Әмирхан каләме тарафыннан классик сатирик әсәрләр тудырылу.Әдип иҗатында әдәби юнәлеш, стиль төрлелеге, аларның синтезы күзәтелү, бу юнәлештә кызыклы тәҗрибәләр ясалу.

***практическое занятие (8 часа(ов)):***

Тема: Гаяз Исхакыйның "таң"чылык чоры иҗаты. 1. Иҗтимагый-сәяси һәм сәнгатьчә фикерләвендәге үзгәрешләр, иҗатында жанр төрлелеге. ?Зиндан? әсәре, аның жанры һәм иҗат методы.. 2. Драматургның Алдым-бирдем драмасында конфликт һәм характерлар. 3. Тормышмы бу романында төп каһарман Миннең фикри-рухи үсеш баскычлары, әсәрнең сәнгати үзенчәлекләре. 4. Тартышу тарихи драмасында гәүдәләнгән иҗтимагый-социаль һәм сыйнфый көрәш мотивлары, татар һәм рус революциясе темаларының чагылышы. 2 раздел Тема: Гаяз Исхакыйның милләтчелек чоры иҗаты. 1. Гаяз Исхакыйның 1910 нчы еллардагы иҗтимагый-милли эшчәнлеге. 2. Иҗтимагый-социаль, мәдәни-рухи, әхлакый мәсьәләләрне гәүдәләндергән күләмле Теләнче кызы романы. Әсәрдә пролетариат әдәбиятына хас сыйфатлар. 3. Зөләйха пьесасы. Аның жанр һәм конфликт үзенчәлеге. Трагедиянең иҗтимагый-милли әһәмияте. 4. Мөгаллимә драмасының конфликты, күтәрелгән мәсьәләләр. Авторның хатын-кызның милли һәм иҗтимагый тормыштагы урыны турында әдипнең уйланулары. Тема:Ф.Әмирхан иҗатында татар тормышын яңарту темасы. 1. Ф.Әмирхан Яңарыш чоры әдибе, реалист һәм романтик язучы, милли әдәбиятны модернистик агымнарның сыйфатлары тасвир-чаралары белән баеткан сүз остасы. 2. Әдип иҗатында татар тормышын яңарту, үзгәртеп кору юллары турында уйланулар, якланган фикерләр (Гарәфә кич төшемдә, Яшьләр, Тигезсезләр һ.б.). 3. Язучының әдәби мирасында яшьләр темасының яктыртылышы, яшьләрнең рухи-фикри, мәдәни үсеш баскычлары. Әсәрнең сюжет, композиция үзенчәлекләре, сәнгатьчә эшләнеше (Яшьләр, Тигезсезләр, Урталыкта һ.б.). Тема:Г.Ибраһимов хикәяче һәм романчы 1. Әдипнең романтик дәвер хикәяләре: Сөю-сәгадәт, Диңгездә, Уты сүнгән җәһәннәм дә яшәү, аның матурлыгын, яшәү мәгънәсен эзләүче герой. Автор мөрәҗәгать иткән алымнар, чаралар. 2. Язучының гади халык тормышын, авыр яшәешен гәүдәләндергән Карт ялчы, Көтүчеләр хикәясе. Г.Ибраһимовның иҗтимагый гаделсезлекләр, әдәбият-сәнгать һәм кешелек җәмгыяте сораулары тирәсендә фәлсәфи, әдәби-эстетик гамьнәре; әсәрләрнең иҗат ысулы мәсьәләсе. 3. Табигать балалары хикәясендә әдипнең фәлсәфи, руссочыл карашлары. Әдәбият-сәнгатьнең вазифасы, дин, фән, гыйлем, милләт турында уйлануларның Мәрхүмнең дәфтәреннән хикәясендә үстерелеше һәм яңача хәл ителеше. 4. Г.Ибраһимовның Яшь йөрәкләр романы: Образлар системасы һәм әсәсрнең сәнгати сыйфатлары.

**Тема 3. Тататрская поэзия начала XX века.**

***лекционное занятие (6 часа(ов)):***


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Тема:XX гасыр башы татар поэзиясе XX йөз башы милли шигъриятенең хронологик чикләре һәм үсеш этаплары (1905-1911; 1912-1917). Беренче рус инкыйлабы елларында татар поэзиясендә күзәтелгән сыйфади үзгәрешләрнең социаль һәм әдәби сәбәпләре. М.Гафури (1880-1934), Н.Думави (1883-1933), С.Рәмиев (1880-1926), М.Укмасый (1884-1946), З.Бәшири (1888-1966) һ.б. шигъриятендә демократик идеяләрнең чагылышы. Алар иҗатында реалистик поэзиянең билгеләре, үзенчәлекләре гәүдәләнү. Шагыйрьләрне берләштергән яклар. Реакция еллары (1908-1910) шигъриятендә сыйфат үзгәрешләре. Аның сәбәпләре. Поэзиянең идея эчтәлегендә, мотивларында, жанрларында барлыкка килгән яңа тенденцияләр. Габдулла Тукай (1886-1913) иҗаты Шагыйрьнең тормыш сукмаклары һәм күпкырлы эшчәнлеге. Тукайны XX гасыр татар поэзиясенең, әдәбиятының үсеш юнәлешен билгеләүче шагыйрь итеп формалаштырган алшартлар. Шагыйрь иҗатын чорларга бүлү мәсьәләсе. Тема:Мәҗит Гафури (1880-1934) иҗаты М.Гафури ? татар-башкорт әдибе, публицист. Аның тәрҗемәи хәле. XX гасыр башында аның поэзия, проза төрләрендә эшчәнлеге. М.Гафури ? реалист шагыйрь. Аның иҗатында тематик байлык һәм жанр төрлелеге. Тема:XX гасыр башында романтик поэзия. XX гасыр башында кеше тормышын сәнгатьчә гәүдәләндерүнең романтик формасы әдәби мәйданга килә. С.Рәмиев ? шагыйрь, прозаик, драматург, журналист, җәмәгать эшлеклесе.. С.Рәмиев лирикасының йөзен билгеләүче төп сыйфатлар. Шагыйрь ? романтик поэзия вәкиле. Анда романтик эстетика атрибутлары: хатын-кыз, мәхәббәт, табигать культларының чагылышы. Дәрдемәнд (Закир Рәмиев) ? шагыйрь, язучы, тыйнак һәм укымышлы зыялы, милләт хадиме. Иҗат юнәлеше һәм иҗтимагый-социаль хәленең үзенчәлеге.Шагыйрьлек тавышының төп сыйфатлары: романтизм, фәлсәфи романтизм. Шигъриятенең символизм модернистик агымы белән бәйләнеше. Аның әдәби һәм фәлсәфи тамырлары.

***практическое занятие (6 часа(ов)):***

Тема:Г.Тукай Яңарыш чоры шагыйре. 1. Тукайның Җаек чоры иҗатында татар халкы, аның үткәне, бүгенгесе, киләчәге һәм милләтнең яшәешен үзгәртү юллары турында уйланулар (Мужик йокысы, Дусларга бер сүз, Иттифак хакында, Милләткә, Кичке азан, Китмибез һ.б.). 2. Шагыйрьнең Казан чоры гражданлык лирикасында үзгәрешләр, хис-кичерешләрнең, халыкчанлыкның тирәнәюе, иҗат принциплары һәм алымнарының төрлеләнүе (Милли моңнар, Көзге җилләр, Өметсезлек һ.б.). 3. Тукай шигъриятендә социаль мотивлар, контрастлар, автор мөрәҗәгать иткән алымнар, чаралар. Лирик геройның борчылу, сызлану сәбәпләре (Яз галәмәтләре, Алтынга каршы, Эштән чыгарылган татар кызына, Буран, Золым, Сайфия, Кярханәдә, Казан вә Кабан арты һ.б.). 4. Тукай рухи мирасында шагыйрь мотивының идея-эстетик гәүдәләнеше (Бер татар шагыйренең сүзләре, Байроннан, Пәйгамбәр һ.б.). Тема:Мәҗит Гафури шигърияте. 1. М.Гафури иҗатында мәгърифәтчелектән тәнкыйди реализмга күчеш, реакция һәм аннан соңгы чор әсәрләрендә романтик (традицион һәм гареб) башлангычның көчәюе. 2. Шагыйрь иҗатында мотивлар төрлелеге. Башлангыч чор шигъриятендәге уку, гыйлем һәм әхлак мәсьәләләреннән иҗтимагый-социаль темаларга борылу.. 3. Шагыйрьнең пейзаж, күңел һәм фәлсәфи лирикасында хис-кичерешләр, бәя-хөкемнәр, фикерләр тирәнлеге. 4. М.Гафури шигъриятендә сугыш темасы. Сугыш характерын аңлау, аны бәяләү юлында лирик геройның эволюциясе, аның борчылу, сызлану сәбәпләре. 5. Әдип мирасында дини мотивлар. Шагыйрь әсәрләрендә дөньяви мәсьәләләрнең дини мотивлар белән үрелеп бирелүе. Поэмаларның сюжет сызыгы, образлары, аларда үткәрелгән фикерләр. Тема:Сәгыйть Рәмиев иҗаты. 1. С.Рәмиев ? гыйсъянчылык романтизмы шагыйре, аның шигъриятендә лирик герой: романтик, матурлыкка гашыйк, бунтарь, ярсу йөрәкле, гыйсъянчы. 2. Шагыйрь әсәрләрендә милләтнең үткәне, бүгенге хәле, киләчәге һәм аны үзгәртү турында уйланулар (Уку, Таң вакыты, Кеше һ.б.). 3. С.Рәмиев шигырьләрендә фәлсәфи-экзистенциаль мотивлар (Дөньяга, Алданган, Мин үләм, Мин һ.б.). 4. Шагыйрь мөрәҗәгать иткән алымнар, аның сүз-сурәт, образ тудыру осталыгы, милли шигърияткә алып килгән яңалыгы

**Тема 4. Татарская драматургия начала XX века.**

***лекционное занятие (2 часа(ов)):***



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Тема:ХХ гасыр башы татар драматургиясе. Татар драматургиясенең беренче адымнары. Милли драматургиянең үсеш баскычлары. Аның мәгърифәтчелек чоры (1887-1905). Иҗат иткән көчләр. Драма әсәрләрендә гәүдәләнгән темалар һәм күтәрелгән мәсьәләләр, алдагы чор әдәбияты белән бәйли торган җепләр. Икенче чор (1906-1911). Татар драматургиясендә барлыкка килгән яңа сыйфатларның, күтәрелешнең тарихи-мәдәни сәбәпләре. Г.Камал, Г.Исхакыйларның иҗат активлыгы. Ф.Әмирхан, С.Рәмиевләрнең язучылык сәләтләрен драма төрендә сынаулары. Бу чор драматургиясенең идея-тематик киңлеге, жанр төрлелеге. Сатирик юнәлешнең үсеше. Татар драматургиясенең өченче чоры (1912-1917). Драматургларның икенче буыны.Тематик яктан, образ-характерлар тудыру алымнарында, конфликт оештыруда барлыкка килгән юнәлешләр, жанрлар системасындагы үзгәрешләр. Чор драматургиясендә әдәби юнәлешләр, агымнар, иҗат методлары мәсьәләсе. Гафур Коләхмәтов (1881-1918) иҗаты. Әдипнең тормыш юлы. Иҗтимагый-сәяси карашлары, инкыйлаби эшчәнлеге. Татар драматургиясенә алып килгән тема, идея яңалыгы, Жанр поэтикасын төрләндерүе.

***практическое занятие (4 часа(ов)):***

Тема: Гафур Коләхмәтов иҗаты. 1.ХХ өз башында татар драматургиясенең үсеш баскыслары6 төп сыйфатлары. 2. Г.Коләхмәтов пролетар агым вәкиле.Аның әдәби мирасында пролетар әдәбият үзенчәлекләре. 2. Ике фикер драмасының тема яңалыгы. Давыт күңелендәге эчке каршылыкның гәүдәләнеше. 3. Драматургның ике сюжет сызыгын колачлаган Яшь гомер драмасы. Әсәрнең конфликт үзенчәлеге. Тема:: Г.Камал комедия остасы. 1. Г.Камал иҗатында сатираның үсеше, аның социаль җирлеге. Беренче театр комедиясе. Пьесада төп һәм ярдәмче каршылыклар. 2. Әдипнең Банкрот һәм Бүләк өчен комедияләре. Пьесаларда комедиографның чагылдыру өлкәсе; ачы көлү һәм фаш итү объектлары; көлке тудыру алымнары һәм чаралары. 3. Безнең шәһәрнең серләре комедиясе, сюжет һәм композиция үзенчәлеге.

### 4.3 Структура и содержание самостоятельной работы дисциплины (модуля)

| N | Раздел Дисциплины | Семестр | Неделя семестра | Виды самостоятельной работы студентов | Трудоемкость (в часах) | Формы контроля самостоятельной работы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тема 1. Введение. Предмет, цели и задачи курса. Культурологическая характеристика начала ХХ века. Литературные направления и течения в татарской литературе Нового времени | 5 | 1-3 | подготовка к творческому экзамену | 2 | творческое задание |
| 2. | Тема 2. Татарская проза начала ХХ века. | 5 | 4-8 | подготовка к контрольной работе | 6 | контрольная работа |
| 3. | Тема 3. Тататрская поэзия начала ХХ века. | 5 | 9-14 | подготовка к тестированию | 6 | тестирование |
| 4. | Тема 4. Татарская драматургия начала ХХ века. | 5 | 15-18 | подготовка к контрольной работе | 4 | контрольная работа |
| | Итого | | | | 18 | |

### 5. Образовательные технологии, включая интерактивные формы обучения


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Рекомендуемые образовательные технологии: лекции, практические занятия, контрольные работы, коллоквиумы, самостоятельные работы, научно-исследовательские работы, творческие работы, курсовые работы.

При проведении занятий используются активные и интерактивные формы занятий (компьютерные симуляции, деловые и ролевые игры, проектные методики, мозговой штурм, разбор конкретных ситуаций) в сочетании с внеаудиторной работой.

В рамках учебного курса предусматриваются встречи с ведущими учеными литературоведами по истории татарской литературы начала XX века, посещение литературных музеев г.Казани и РТ, отдела редких книг и рукописей научной библиотеки КФУ им. Н.Лобачевского и архивов РТ.

## 6. Оценочные средства для текущего контроля успеваемости, промежуточной аттестации по итогам освоения дисциплины и учебно-методическое обеспечение самостоятельной работы студентов

### Тема 1. Введение. Предмет, цели и задачи курса. Культурологическая характеристика начала XX века. Литературные направления и течения в татарской литературе Нового времени

творческое задание , примерные вопросы:

) творческие работы (по произведениям Ф.Амирхана ?Перепутье?, Г.Исхаки ?Нищенка?, Г.Ибрагимова ?Наши дни?) (XX йөз башы татар романнарында характерлар үсеше һәм сюжет сызыклары (Г.Ибраһимов ?Яшь йөрәкләр?, ?Безнең көннәр?; Г.Исхакый ?Теләнче кызы?; Ф.Әмирхан ?Урталыкта? һәм Г.Исхакыйның ?Ике йөз елдан соң инкыйраз? повесте) 1. Г.Ибраһимовның ?Безнең көннәр? романында Зариф Булатов белән бәйле сюжет сызыгы, аның сәяси эшчәнлеге. 2. Г.Исхакыйның ?Теләнче кызы? романында Сәгадәт образы, халыкчылык идеяләренең гәүдәләнеше. 3. Г.Ибраһимовның ?Безнең көннәр? романында Гәрәй Солтан образы, аның белән бәйле сюжет сызыгы. 4. Г.Ибраһимовның ?Безнең көннәр? романында Әхтәм Таңгатаров образы. 5. Г.Ибраһимовның ?Яшь йөрәкләр? романында татар тормышын яңартуда музыканың роле турында. 6. Ф.Әмирханның ?Урталыкта? романында Хәсән Арсланов белән бәйле вакыйгалар, аның характер сыйфатлары. 7. Г.Исхакыйның ?Ике йөз елдан соң инкыйраз? повестенда XX гасырда сурәтләнгән инкыйраз күренешләре. 8. Г.Ибраһимовның ?Безнең көннәр? романында жандарм Герасимов образы. 9. Г.Ибраһимовның ?Яшь йөрәкләр? романында морзалар тормышының сурәтләнеше. 10. Г.Исхакыйның ?Ике йөз елдан соң инкыйраз? повестенда сурәтләнгән татарларны инкыйразга алып килгән ?курчак туйлары?.

### Тема 2. Татарская проза начала XX века.

контрольная работа , примерные вопросы:

Контроль эш (7-8 атна) I вариант 1. Татар әдәби тәнкыйте барлыкка килү һәм аның татар әдәбиятына йогынтысы. 2. Романтизм юнәлеше, яңа тип (гареб) романтизм формалашу, аның төп сыйфатлары. 3. С.Рәмиевнең ?Яшә, Зөбәйдә, яшим мин? драмасында феминистик (хатын-кыз) мотивлары. II вариант 1. XX гасыр башы татар әдәбияты. Аның яңа күтәрелеше. Өйрәнелү тарихы. 2. Тәнкыйди реализм калыплашу: аның асылы, төп принциплары. 3. К.Тинчуринның ?Соңгы сәлам? драмасында үзәк конфликт, аның үзенчәлеге. III вариант 1. Милли драматургиянең ?театрлы? икенче чоры, төп үсеш тенденцияләре. 2. Романтизм юнәлеше, яңа тип (гареб) романтизм формалашу, аның төп сыйфатлары. 3. Ф.Әмирханның ?Яшьләр? драмасында ?аталар? һәм ?балалар? тартышының гәүдәләнеше. IV вариант 1. Вакытлы матбугат туу һәм аның милли әдәбият үсешенә уңай йогынтысы. 2. Тәнкыйди реализм калыплашу: аның асылы, төп принциплары. 3. Г.Камалның ?Бәхетсез егет? драмасында уку, гыйлем һәм тәрбия мәсьәләләренең

### Тема 3. Тататрская поэзия начала XX века.

тестирование , примерные вопросы:



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Ябык Җиңел 1. ?Әдәбият мәйданында хәзер иң шәүкәтле вә иң бөек урында карт реалист Гаяз әфәнде тора? юлларының авторы: а) Җ.Вәлиди в) Г.Ибраһимов б) Ф.Әмирхан 2. Г.Исхакый гомеренең соңгы көннәрен үткәргән дәүләт: а) Германия б) Төркия в) Финляндия г) Польша 3. ?Тартышуда табарсың син үзеңнең хакыңны!? шигаре Г.Исхакый иҗатының кайсы чорына карый? а) мәгърифәтчелек б) ?таңчы?лык в) милләтчелек 4. Ф.Әмирханның рус әдибе И.С.Тургенев иҗаты йогынтысында язылган әсәре: а) ?Урталыкта? в) ?Яшьләр? б) ?Тигезсезләр? г) ?Хәят? 5. Г.Ибраһимов иң актив язышкан матбугат органы: а) ?Аң? в) ?Балалар дөньясы? б) ?Шура? г) ?Мәктәп? Уртача 6. ?Ике йөз елдан соң инкыйраз? әсәренең үзәген тәшкил иткән төп мәсьәлә: а) татар милләтенең инкыйразы б) татарларны урыслаштыру сәясәте в) хатын-кыз азатлыгы г) әдәбият, сәнгать, музыка мәсьәләсе 7. Ф.Әмирхан нинди иҗат тибы әдибе? а) реалист в) реалист-романтик б) романтик г) модернистик 8. Ф.Әмирхан иҗатында киң яктыртылган тема: а) мәхәббәт темасы в) тарихи тема б) яшьләр темасы г) сыйнфый көрәш вакыйгалары 9. Г.Ибраһимовның кайсы каһарманын Г.Исхакыйның мәхдүме (?Тормышмы бу??) белән бер рәткә куярга мөмкин булыр иде? а) Сабир г) Җәмил б) Сәлим д) Тимри в) Садыйк 10. ?Акчарлаклар? (Ш.Камал) повестендагы ?акчарлаклар? образының (троплар) төре: а) эпитет г) метафора б) сынландыру д) аллегория в) метонимия Авыр 11. Төп геройның эш-гамәлләрен бәяләүче буларак Зөһрә кыз мифологик образы килеп кергән Г.Исхакыйның әсәре: а) ?Теләнче кызы? б) ?Тормышмы бу?? в) ?Мәдрәсә җимеше? 12. ?Хәят? повестендагы сюжет вакыты: а) май аеннан алып икенче елның җәенә кадәр б) 16 ел в) өч ел 13. Г.Ибраһимовның иҗат концепциясендә кире кагылган мәхәббәт төре: а) әфләтүн г) бала б) ана д) тән в) туганлык е) гомумхалык 14. ?Печән базары, яхуд Яңа Кисекбаш? поэмасын тәнкыйди реализм үрнәге иткән сыйфат: а) вакыйга, хәл-күренешләрнең реаль җирлеге б) типиклаштыру, гомумиләштерү в) чынбарлыкны сурәтләүнең рухи принцибы г) кешенең рухи дөньясына табигать күренешләренең янәшә куелуы

**Тема 4. Татарская драматургия начала XX века.**

контрольная работа , примерные вопросы:

вариант 1. С. Рәмиев шигъриятендә лирик герой, шәхес бунты, романтик мәхәббәт. Гыйсъянчылык романтизмы. (?Таң вакыты?, ?Мин?, ?Син?, ?Ул?, ?Алданган?, ?Дөньяга?, ?Авыл? һ.б.). Бер шигырен яттан сөйләргә. 2. Г.Тукай (II вариант тест биреме). II вариант 1. Ш. Бабичның тормыш юлы һәм күпкырлы эшчәнлеге. Лирикасының төп сыйфатлары (?Бәхетем?, ?Шатлык җыры?, ?Халкым өчен?, ?Бәнем фәрештәм?, ?Скрипка?, ?Бер минут?, ?Тын төн?, ?Габдулла әфәнде Тукаев?, ?Ике аккош?, ?Утрау? һ.б. 2. М.Гафури ( I вариант тест биреме). III вариант 1. Дәрдемәнд лирикасы; шигырьләрендә чагылган фәлсәфи уйланулар, сагыш, гамь. Символизм. Бер ? ике шигырен яттан сөйләргә. 2. Н.Думави (I вариант тест биреме). IV вариант 1. Г. Тукайның Җаек чоры иҗаты: иҗтимагый һәм әдәби ? эстетик карашлары (?Мужик йокысы?, ?Дусларга бер сүз?, ?Хөррият хакында?, ?Государственная думага?, ?Алтынга каршы?, ?Сорыкортларга?, ?Китмибез?, ?Шүрәле?, ?Милләткә?, ?Үз ? үземә? һ.б.). 2. Ш.Бабич (II вариант тест биреме).

**Тема . Итоговая форма контроля**

Примерные вопросы к экзамену:

Перечень вопросов для экзамена (экзаменга сораулар):

1. XX йөз башы татар әдәбияты. Өйрәнелү тарихы. Чор үзенчәлеге. Сүз сәнгате үсешенең яңа күтәрелеше.

2. XX йөз башы татар әдәбиятында сатира, аның җирлеге. Милли әдәбиятта сатираны үткенәйтүче алымнар. Ш. Камалның "Хаҗи әфәнде өйләнә" комедиясе.

3. XX йөз башы татар прозасында тарихи теманың гәүдәләнеше. (Ф. Әмирхан, М. Гафури, Н. Думави, Ш. Әхмәдиев һ.б.). "Сөенбикә", "Хан кызы Алтынчәч", "Хан кызы", "Болгар кызы Тойгы туташ" һ.б.

4. 1905 - 1907 еллар инкыйлабы нәтиҗәсе буларак татар вакытлы матбугаты барлыкка килү һәм аның әдәбият үсеше өчен әһәмияте.

5. Татар әдәбиятында романтизмның әдәби агым буларак формалашуы, сәбәпләре, милли әдәбиятка романтизм алып килгән сыйфатлар.

6. Татар әдәби тәнкыйтенең формалашуы, бурычлары. (Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Г. Тукай, Җ. Вәлиди һ.б.).


ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

7. Татар әдәбиятында морзалар тормышының чагылышы. Аның тарихи традицияләре. (Ф. Әмирхан, Г. Ибраһимов, С. Җәләл һ.б.). С. Җәләлнең "Дим буенда" повесте.

8. Татар әдәбиятында тәнкыйди реализмның формалашуы. Аның асылы, иҗат методы буларак принциплары, тарихи традицияләре.

9. Милли драматургиянең икенче баскычы (1906 - 1911). Татар профессиональ театры формалашу һәм аның драматургия үсешенә уңай йогынтысы.

10. Г. Тукайның Җаек чоры иҗаты: иҗтимагый һәм әдәби - эстетик карашлары ("Мужик йокысы", "Дустларга бер сүз", "Хөррият хакында", "Государственная думага", "Алтынга каршы", "Сорыкортларга", "Китмибез", "Шүрәле", "Милләткә", "Үз - үземә" һ.б.).

11. Г. Тукайның Казан чоры иҗаты: гражданлык һәм күңел лирикасы ("Өмидсезлек", "Җәйге таң хатирәсе", "Милли моңнар", "Шагыйрь", "Пәйгамбәр" "Сайфия", "Кыйтга", "Хәстә хәле", һ.б.).

12. Г. Тукай сатирик иҗаты, сәнгати алымнар төрлелеге. ("Сорыкортларга", "Пыяла баш", "Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш", "Милләтчеләр",Авыл халкына ни җитми һ.б. )

13. Г. Исхакыйның октябрьгә кадәрге иҗатында мәгърифәтчелек, социаль тигезсезлек, милли һ.б.мәсьәләләр чагылышы ("Ике йөз елдан соң инкыйраз", "Зиндан", Зөләйха", "Ул әле өйләнмәгән иде" һ.б.)

14. Г.Исхакыйның мөһаҗирлектәге тормышы һәм иҗаты. "Олуг Мөхәммәд" тарихи драмасы.

15. Г. Ибраһимовның беренче чор (1908 - 1912) иҗатының төп сыйфатлары. "Яз башы", "Диңгездә", "Сөю - сәгадәт" һ.б. әсәрләрендә кеше, аның асылы, гомер агышы, мәхәббәт хакында уйланулар.

16. Г. Ибраһимовның икенче чор (1913 - 1917) иҗаты. "Безнең көннәр" романы: идея эчтәлеге һәм сәнгатьчә эшләнеше.

17. Г. Ибраһимовның "Яшь йөрәкләр" романында романтик шәхесләр, иске татар тормышының гәүдәләнеше, кеше һәм сәнгать мөнәсәбәте.

18. Г. Ибраһимов хикәяләрендә кеше бәхете, яшәү мәгънәсе, әдәбият - сәнгать мәсьәләләренең чагылышы. ("Карт ялчы", "Уты сүнгән җәһәннәм", "Табигать балалар", "Мәрхүмнең дәфтәреннән" һ.б.).

19. Н. Думави шигърияте. "Берлек - иттифак", "Ревалюция заманы", "Эч поша, күңел болгана", "Мәңгелек мәхбүс", "Бизмә дөньядан", "Беренче кар", "Мәхәббәт", "Сугыш", "Сугыш тәэссораты" һ.б. Экспрессионизм.

20. Н. Думави хикәяләре: идея - эстетик үзенчәлекләре (реалистик, романтик, модернистик катламнарның чагылышы). "Кем гаепле", "Мортый илә Мукай", "Су кызы", "Карт мөгаллимнәр" һ.б.

21. Ф. Әмирханның драматургия төрендә эшчәнлеге. "Яшьләр" һәм "Тигезсезләр" пьесаларының идея - эстетик үзенчәлекләре.

22. Ф. Әмирхан прозасы: тематика һәм поэтика "Татар кызы", "Хәят","Кадерле минутлар", "Бер хәрабәдә" һ.б.

23. Ф. Әмирханның сатирасында көлү, тәнкыйтьләү объектлары, сурәтләү алымнары ("Бәйрәмнәр", "Фәтхулла хәзрәт", "Хәзрәт үгетләргә килде" һ.б.).

24. Г. Коләхмәтов драматургиясе: "Ике фикер", "Яшь гомер" һ.б. Бу төргә әдип алып килгән яңа сыйфатлар.

25. Г. Камалның күпкырлы эшчәнлеге. Әдипнең татар драматургиясен үстерүгә керткән өлеше. "Бәхетсез егет", "Уйнаш" драмаларында конфликт, аларның сәнгатьчә хәл ителеше.

26. Г. Камал - комедия остасы, "Беренче театр", "Банкрот", "Бүләк өчен" пьесаларында көлү, фаш итү объектлары һәм алымнары.

27. С. Рәмиев шигъриятендә лирик герой, шәхес бунты, романтик мәхәббәт. Гыйсъянчылык романтизмы. ("Таң вакыты", "Мин", "Син", "Ул", "Алданган", "Дөньяга", "Авыл" һ.б.). Бер шигырен яттан сөйләргә.

28. С. Рәмиевнең проза һәм драма төрләрендә эшчәнлеге. "Низамлы мәдрәсә", "Яшә, Зөбәйдә, яшим мин" пьесаларында төп һәм ярдәмче каршылыклар, күтәрелгән иҗтимагый - милли проблемалар, аларның хәл ителеше.

29. Ш. Камал әсәрендә бәхет темасының яктырылышы. Язучы мөрәҗәгать иткән алымнар ("Козгыннар оясында", "Сукбай", "Бәхет эзләгәндә", "Акчарлаклар" һ.б.).

30. Ш. Камал иҗаты. ("Сулган гөл", "Уяну", "Буранда", " Тормыш көе", "Курай", "Курай тавышы" һ.б.). Кеше тормышын, аның күңел дөньясын сурәтләүдә әдип осталыгы. Импрессионизм.

31. М. Гафуриның Беренче рус инкыйлабы һәм реакция еллары шигърияте, анда чор сулышы, иҗтимагый, социаль мотивлар гәүдәләнеше "Шатлык шигыре", "Хөррият дәверендә" "1906 нчы елдан 1907 елга васыять", "Базарга чыктым", "Татар хатыны", "Яфрак", "Үтә гомерем", "Харап булган бакча", "Әтәч белән сандугач" һ.б.

32. М. Гафуриның 1910-еллар поэзиясендә лирик герой; жанр һәм мотивлар төрлелеге: "Үзем һәм халкым", "Мин кайда", "Хакыйкать", "Тормыш", "Г. Тукай вафатыннан соң", "Беренче мәхәббәт", "Хәят юлында", "Юктырсың ла, Алла" һ.б.

33. М. Фәйзинең драматургиясе. "Яшьләр алдатмыйлар", "Кызганыч", "Галиябану" пьесаларының идея - проблематикасы һәм сәнгатьчә эшләнеше.

34. Дәрдемәнд лирикасы; шигырьләрендә чагылган фәлсәфи уйланулар, сагыш, гамь. Символизм. Бер - ике шигырен яттан сөйләргә.

35. Ш. Бабичның лирик иҗаты һәм поэмалары. Лирикасының төп сыйфатлары ("Бәхетем", "Халкым өчен", "Бәнем фәрештәм", "Скрипка", "Бер минут", "Тын төн", "Габдулла әфәнде Тукаев", "Ике аккош", "Утрау" һ.б.). "Кандала" , "Газазил" поэмалары. Әдип сатирасының үзенчәлеге.

36. Әдәби иҗатка 1910 елларда килгән икенче буын прозаиклар. Г. Рәхим, Ш. Әхмәдиев һ.б. лар: "Галия" , "Көзге хикәя" , "Яз әкиятләре", "Мөгаллим", "Кеше", "Шагыйрь моңая", "Суга баткан килен" һ.б.)

### 7.1. Основная литература:

1. Яхин Ф.З. Гасырдан - гасырга [Текст: электронный ресурс] : яңа заман әдәбиятына / Фәрит Яхин .? Электронные данные (1 файл: 1,17 Мб) .? (Казань : Казанский федеральный университет, 2014) .? Загл. с экрана .? Режим доступа: открытый URL:http://libweb.kpfu.ru/publication/book/978-5-98356-233-2.pdf

2. Гыйлаҗев Т. Татар әдәбияты. XX гасыр башы (Лекцияләр, гамәли дәресләр, тестлар).- Казан: Мәгариф, 2007.

3. Гилазов Т.Ш. История татарской литературы начала XX века. http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=1901 ЭОР

4. Заһидуллина Д. Дөнья сурәте үзгәрү. XX йөз башы татар әдәбиятында фәлсәфи әсәрләр. Монография. - Казан: Мәгариф, 2006. - 191 б

### 7.2. Дополнительная литература:

1. Гыйлаҗев Т. Әдәби мирас: тарих hәм заман (Тукай фәне. Әдәби тәнкыйть. XX гасыр башы татар әдәбиятында традицияләр һәм яңачалык).- (кереш сүз авторы Д.Ф.Заhидуллина).- Казан:Татар. кит. нәшр., 2005.- 206 б.

2. Закирҗанов Ә. Яңарыш юлыннан (Хәзерге татар әдәбият белеме мәсьәләләре). ("XX йөз башы сүз сәнгатен өйрәнүдә яңа табышлар" дигән бүлек. 99-112 б.б. ).-Казан: Татар. кит. нәшр., 2008.-303 б.

3. Татар шигърияте. XX гасыр башы (З.Р.Вәлиева, А.Г.Әхмәдуллин, Р.И.Вәлиев, Т.Н.Галиуллин, Д.Ф.Заhидуллина, Х.Й.Миннегулов, Н.Ш.Хисамов, М.Х.Вәлиев).- Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.-447б.

4. Эпик шигърият. XX йөз башы (ред. Ф.З.Яхин) Казан: ТАрих, 2002.- 463 б.

5. Заһидуллина Д.Ф. Татар әдәбияты: Теория. Тарих / Д.Ф.Заһидуллина, Ә.М.Закирҗанов, Т.Ш.Гыйләҗев, Н.М.Йосыпова.- Казан: Мәгариф, 2006. - 319 б.

6. История русской литературы XX века: Учебник / В.Д. Серафимова. - М.: НИЦ Инфра-М, 2013. - 540 chttp://znanium.com/catalog.php?bookinfo=346858

7. Гыйлаҗев Т.Ш.Мирхәйдәр Фәйзи: Тормыш юлы һәм иҗаты / Уку-укыту әсбабы. - Казан: Казан университеты, 2011. - 80 б.

8. Татар әдәбияты тарихы. Алты томда. 3-т (XX гасыр башы). Том. ред. Халитов Г.М., Гыйззәтуллин Н.Г., Әхмәдуллин А.Г. һ.б. - Казан: Татар кит.нәшр., 1986. - 598 б.

9. Заһидуллина Д.Ф., Йосыпова Н.М. XX гасыр татар әдәбияты тарихы: дәреслек. - Казан: Казан университеты, 2011. - 1 нче китап: XX йөзнең беренче яртысында татар әдәбияты. - 230 б.

10. Ганиева Р. К. Традиции Восточного Ренессанса в тюрских литературах Средневековья и Нового времени. - Казань: Изд-во "Фән" АН РТ, 2014. 272 с.

11. Нуруллин И. XX йөз башы татар әдәбияты. - Казан: Татар кит.нәшр., 1982. - 285 б.

12. Бәширов Ф. XX йөз башы татар прозасы. - Казан: Фикер, 2002. - 284 б.

13. Ганиева Р. Татар әдәбияты: традицияләр, бәйләнешләр. - Казан: Университет нәшрияты, 2002. - 272 б.

14. Заһидуллина Д. XX йөз башы татар прозасы һәм модернизм. - Казан: Татар кит.нәшр., 2003. - 254 б.

15. Литовченко М.В. Теория и история литературы: Проблема преемственночти в развитии русской литературы XIXв. Учебное пособие для студентов / М.В.Литовченко. - Кемерово: КемГУКИ, 2011. - 72 с. http://www.bibliorossica.com ЭБС "Библиороссия".

16. История русской литературы конца XIX - начала XX века: учебное пособие для студентов высших учебных заведений, обучающихся по направлению 031000 и специальности 031001 - Филология: в 2 т. / под ред. В. А. Келдыша.-2-е изд., Москва: Академия, 2009.

17. 12. Гилазов Т.Ш. История татарской литературной критики http://tulpar.kfu.ru/course/view.php?id=2018

### 7.3. Интернет-ресурсы:

КНИГОФОНД - knigafund.ru

КФУ - Научная библиотека им. Н.И.Лобачевского - lsl.ksu.ru

Научная библиотека им. Н.И.Лобачевского Казанского ... - g-egorov.livejournal.com/115591.html

Научная библиотека им.Лобачевского Казанского университета - lsl.ksu.ru

Электронная Библиотека КГУ / Каталог Книг - library.ksu.ru

### 8. Материально-техническое обеспечение дисциплины(модуля)

Освоение дисциплины "Татарская литература начала 20 века" предполагает использование следующего материально-технического обеспечения:

Мультимедийная аудитория, вместимостью более 60 человек. Мультимедийная аудитория состоит из интегрированных инженерных систем с единой системой управления, оснащенная современными средствами воспроизведения и визуализации любой видео и аудио информации, получения и передачи электронных документов. Типовая комплектация мультимедийной аудитории состоит из: мультимедийного проектора, автоматизированного проекционного экрана, акустической системы, а также интерактивной трибуны преподавателя, включающей тач-скрин монитор с диагональю не менее 22 дюймов, персональный компьютер (с техническими характеристиками не ниже Intel Core i3-2100, DDR3 4096Mb, 500Gb), конференц-микрофон, беспроводной микрофон, блок управления оборудованием, интерфейсы подключения: USB,audio, HDMI. Интерактивная трибуна преподавателя является ключевым элементом управления, объединяющим все устройства в единую систему, и служит полноценным рабочим местом преподавателя. Преподаватель имеет возможность легко управлять всей системой, не отходя от трибуны, что позволяет проводить лекции, практические занятия, презентации, вебинары, конференции и другие виды аудиторной нагрузки обучающихся в удобной и доступной для них форме с применением современных интерактивных средств обучения, в том числе с использованием в процессе обучения всех корпоративных ресурсов. Мультимедийная аудитория также оснащена широкополосным доступом в сеть интернет. Компьютерное оборудованием имеет соответствующее лицензионное программное обеспечение.

Компьютерный класс, представляющий собой рабочее место преподавателя и не менее 15 рабочих мест студентов, включающих компьютерный стол, стул, персональный компьютер, лицензионное программное обеспечение. Каждый компьютер имеет широкополосный доступ в сеть Интернет. Все компьютеры подключены к корпоративной компьютерной сети КФУ и находятся в едином домене.

Учебно-методическая литература для данной дисциплины имеется в наличии в электронно-библиотечной системе " БиблиоРоссика", доступ к которой предоставлен студентам. В ЭБС " БиблиоРоссика " представлены коллекции актуальной научной и учебной литературы по гуманитарным наукам, включающие в себя публикации ведущих российских издательств гуманитарной литературы, издания на английском языке ведущих американских и европейских издательств, а также редкие и малотиражные издания российских региональных вузов. ЭБС "БиблиоРоссика" обеспечивает широкий законный доступ к необходимым для образовательного процесса изданиям с использованием инновационных технологий и соответствует всем требованиям федеральных государственных образовательных стандартов высшего профессионального образования (ФГОС ВПО) нового поколения.

Оргтехника, теле- и аудиоаппаратура, виртуальная и электронная библиотека учебно-методической литературы, доступ к сети Интернет.

Программа составлена в соответствии с требованиями ФГОС ВПО и учебным планом по направлению 44.03.05 "Педагогическое образование (с двумя профилями подготовки)" и профилю подготовки Родной (татарский) язык и литература и иностранный язык (английский) .



ЭЛЕКТРОННЫЙ УНИВЕРСИТЕТ
ИНФОРМАЦИОННО-АНАЛИТИЧЕСКАЯ СИСТЕМА КФУ

Автор(ы):
Гилазов Т.Ш. ____________________
"__" _________ 201 __ г.

Рецензент(ы):
Закирзянов А.М. ____________________
"__" _________ 201 __ г.